# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Президентын
сайлаулар турында

Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

<u>1 статья.</u> "Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында" 1991 елның 13 маендагы Татарстан Республикасы Законына, түбәндәгечә бәян итеп, үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

"Татарстан Республикасы Президентын
сайлаулар турында

Татарстан Республикасы
З А К О Н Ы

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

<u>1 статья.</u> Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның төп принциплары

Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы гражданнары тарафыннан гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә яшерен тавыш бирү юлы белән сайлана.

Сайлаучылар сайлауларда бертигез шартларда катнашалар һәм Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны яклап яисә аңа каршы шәхсән тавыш бирәләр.

Сайлаучыларның ихтыяр белдерүен тикшереп тору тыела.

2 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турында законнар

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар турындагы законнар Татарстан Республикасы Конституциясеннән, әлеге Законнан һәм башка законнардан гыйбарәт.

3 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаганда Татарстан Республикасы гражданнарының сайлау хокуклары

Сайлаулар көненә 18 яшькә җиткән Татарстан Республикасы гражданы Татарстан Республикасы Президентын сайларга хаклы.

Татарстан Республикасы Президенты итеп Татарстан Республикасының утыз биш яшьтән дә яшьрәк булмаган, алтмыш биш яшьтән дә олырак булмаган, Татарстан Республикасы территориясендә кимендә ун ел даими рәвештә яшәгән, сайлау хокукына ия булган һәм Татарстан Республикасының ике дәүләт телен дә белгән гражданы сайланырга мөмкин. Бер үк зат ике чордан да артык Татарстан Республикасы Президенты була алмый.

Суд тарафыннан хокукый сәләтсез дип табылган һәм хөкем карары нигезендә ирегеннән мәхрүм итү урыннарында тотылучы затлар, шулай ук психиатрия сырхауханәләрендә ятып дәваланучы психик авыру гражданнар сайлауларда катнаша алмый.

4 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар, Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләренең конституциячел чоры тәмамланырга өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Президенты сайланган конституциячел чор ул сайланган көннән башлап исәпләнә.

Татарстан Республикасы законнары нигезендә һәм аларда каралган тәртиптә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары тарафыннан һәм Татарстан Республикасы Президенты ризалыгы нигезендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар башка ва-

кытка да күчерелергә мөмкин, әмма ул өч айдан да артык булмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты үз вәкаләтләрен башкаруны конституциячел чор узганчы ук Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган очракларда һәм тәртиптә туктатса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны вакытыннан алда билгели. Бу очракта сайлаулар Татарстан Республикасы Президенты үз вәкаләтләрен башкаруны вакытыннан алда туктаткан көннән башлап ике ай эчендә билгеләнә. Мондый чакта әлеге Законда билгеләнгән сайлау гамәлләре чоры өчтән бергә кими.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны билгеләү турындагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

<u>5 статья.</u> Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар Татарстан Республикасының бөтен территориясен үз эченә алган бердәм республика сайлау округы буенча уздырыла.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру сайлау комиссияләре тарафыннан башкарыла.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда сайлау комиссияләре дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан үз вәкаләтләре чикләрендә бәйсез булалар.

<u>6 статья.</u> Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар тәкъдим итү хокукы

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар тәкъдим итү хокукына түбәндәгеләр ия:

сайлаучыларның эш (уку, хезмәт) һәм яшәү урыны буенча җыелышлары;

һөнәр берлекләре һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлгән фиркаләр, республиканың башка җәмәгать берләшмәләре, шулай ук уставларында Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар ка-

ралган һәм җәмәгать берләшмәләре реестрына кертелгән республика оешмалары (бүлекләре, филиаллары).

Фиркаләр, һөнәр берлекләре, республика җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалары (бүлекләре, филиаллары) җәмәгать берләшмәләре блокларын (алга таба сайлау берләшмәләре дип аталачак) төзергә хаклы, бу очракта алар бер генә сайлау берләшмәсе составына керә алалар. Сайлау берләшмәсе составына кергән фиркаләр, һөнәр берлекләре, республика җәмәгать берләшмәләре һәм оешмалары (бүлекләре, филиаллары) Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны мөстәкыйль рәвештә тәкъдим итү хокукын югалталар.

Кандидатларны тәкъдим итү хокукына ия булучы фиркаләрнең, һөнәр берләкләренең һәм республиканың башка җәмәгать берләшмәләренең һәм оешмаларының исемлеге, сайлаулар көнен игълан иткәннән соң 7 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

7 статья. Сайлау алды үгетләве хокукы

Дәүләт әлеге Закон нигезендә Татарстан Республикасы гражданнарына һәм җәмәгать берләшмәләренә сайлау алды үгетләвен ирекле уздыруны тәэмин итә.

Татарстан Республикасы гражданнары, хезмәт коллективлары һәм җәмәгать берләшмәләре Татарстан Республикасы Президенты урынына чыгучы теге яисә бу кандидатны яклап яки каршы тавыш бирүгә сайлаучыларны өндәүче эшчәнлекне законда рөхсәт ителгән рәвешләрдә һәм законлы ысуллар белән башкарырга хаклы.

Татарстан Республикасы Президенты урынына чыгучы кандидатларга дәүләтнең массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясау өчен бертигез шартлар гарантияләнә.

8 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны финанслау

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга әзерләнү һәм уздыру белән бәйле гамәлләрне финанслау Татарстан Республикасының республика бюджеты исәбеннән башкарыла.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар сайлау алды үгетләвен финанслау өчен үз сайлау фондларын төзергә мөмкин.

9 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда хәбәрдарлык

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру ачык һәм хәбәрдар рәвештә гамәлгә ашырыла.

Сайлау комиссияләренең, дәүләт хакимияте органнарының һәм жирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру белән бәйле һәм гражданнарның сайлау хокукларына кагылышлы карарлары бастырып чыгарылырга тиеш.

## II бүлек. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны оештыру

10 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләре системасы

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне түбәндәгеләр башкара:

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе;

территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссияләре;

участок сайлау комиссияләре.

11 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе

Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны башкаручы сайлау комиссияләре эшчәнлегенә житәкчелек итә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк

сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар көнен билгеләү турындагы карар кабул ителү белән бер үк вакытта комиссия рәисе һәм егерме әгъза составында төзелә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең составы, җәмәгать берләшмәләренең, район, шәһәр дәүләт хакимиятләренең вәкиллекле органнарының, хакимият башлыкларының, сайлаучыларның эш, хезмәт, уку, яшәү урыны буенча җыелышларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан раслана. Бу очракта комиссия әгъзаларының яртысын - Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, ә икенче яртысын Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим итә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе рәисен Татарстан Республикасы Президенты тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы раслый.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы халык депутатларын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе башкарырга мөмкин.

## 12 статья. Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясен төзү тәртибе

Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясе, сайлаулар көненә 75 көннән дә сонга калмыйча, 10-18 әгъзадан төзелә. Территория сайлау комиссиясенең составын район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органнары раслый. Территория сайлау комиссиясенең рәисен район, шәһәр, шәһәрдәге район хакимияте башлыгы тәкъдиме буенча дәүләт хакимиятенең шул ук органы раслый. Бу очракта территория сайлау комиссиясе әгъзаларының яртысын - район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органы президиумы, ә икенче яртысын тиешле җирле хакимият башлыгы тәкъдим итә.

Әгәр район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органы территория сайлау комиссиясе составын билгеләнгән вакытка расламаса йә әлеге территориядә мондый орган булмаса, территория сайлау комиссиясен Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе төзи.

185



Территория сайлау комиссиясе составына кандидатураларны билгеләгәндә район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органы президиумы җәмәгать берләшмәләренең, сайлаучыларның эш, хезмәт, уку һәм яшәү урыны буенча җыелышларының тәкъдимнәрен исәпкә ала.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча территория сайлау комиссияләренең вәкаләтләрен дәүләт хакимиятенең тиешле органнары карары нигезендә җирле Советларның халык депутатларын сайлаулар буенча район, шәһәр, шәһәрдәге район сайлау комиссияләре башкарырга мөмкин.

13 статья. Участок сайлау комиссиясен төзү тәртибе

Участок сайлау комиссиясе, сайлаулар көненә 60 көннән дә соңга калмыйча, җәмәгать берләшмәләренең, эш, хезмәт, уку һәм яшәү урыны буенча сайлаучылар җыелышларының тәкъдимнәрен исәпкә алып, тиешле җирле хакимият башлыгы тәкъдиме буенча, район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органы тарафыннан комиссия рәисе һәм 6-12 әгъза составында төзелә.

Әгәр район, шәһәр, шәһәрдәге район дәүләт хакимиятенең вәкиллекле органы участок сайлау комиссиясе составын билгеләнгән вакытка расламаса йә әлеге территориядә мондый орган булмаса, участок сайлау комиссиясен тиешле территория сайлау комиссиясе төзи.

14 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең вәкаләтләре

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә түбәндәгеләрне башкара:

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча сайлау комиссияләре эшчәнлегенә җитәкчелек итә;

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләгәндә һәм уздырганда законлылык үтәлешен тикшереп тора, әлеге Законның бер генә төрле кулланылышын тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру белән шөгыльләнүче барлык сайлау комиссияләре өчен дә үтәлеше мәҗбүри булган һәм әлеге Законны куллану мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр һәм башка актлар бастырып чыгара;

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашучы сайлау берләшмәләрен һәм сайлау блокларын терки;

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны һәм аларның ышанычлы затларын терки;

кандидатларга һәм аларның ышанычлы затларына мәгълүм үрнәктәге таныклыклар бирә;

Татарстан Республикасы Президенты урынын дәгъвалаучы барлык кандидатлар өчен сайлау алды эшчәнлегендә бертигез хокукый шартлар тәэмин итә;

министрлыкларның һәм ведомстволарның, башкарма хакимиятнең бүтән органнарының һәм җирле үзидарә органнарының сайлауларны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләренә кагылышлы хәбәрләрен тыңлый;

сайлау бюллетененең, сайлаучылар исемлекләренең һәм башка сайлау документларының рәвешләрен билгели;

сайлау бюллетененең татар һәм урыс телләрендәге текстларын раслый;

сайлау участокларының номерларын билгели;

сайлау комиссияләре мөһерләренең үрнәкләрен һәм сайлау документларын җибәрү һәм саклау тәртибен раслый;

сайлауларны финанс белән тәэмин итү өчен республика бюджетыннан бирелгән акчаларны бүлеп бирә һәм әлеге акчаларның максатчыл кулланылышын тикшереп тора;

сайлау комиссияләренең биналар, транспорт, элемтә белән тәэмин ителешен тикшереп тора һәм сайлауларны матди-техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

түбәнгерәк сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (эш итмәүләренә) карата белдерелгән шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

тавыш бирү йомгакларын эшкәртүнең бердәм тәртибен билгели;

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгели һәм аларны матбугатта бастырып чыгара;

сайлауларны әзерләү һәм уздыру белән бәйле документларны

архивларга тапшыра;

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча кабат тавыш бирүне оештыра;

Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлауларны оештыра;

әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка законнары нигезендә бүтән вәкаләтләр башкара.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарларын үтәү барлык дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, дәүләт предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары, шулай ук урындагы затлар өчен мәҗбүри.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе хокукый зат була һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең яңа составын төзегәнчегә кадәр эшли.

<u>15 статья.</u> Территория (район, шәһәр, шәһәрдәге район) сайлау комиссиясенең вәкаләтләре

Территория сайлау комиссиясе:

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны тиешле территориядә әзерләүне һәм үткәрүне оештыра;

тиешле территориядә участок сайлау комиссияләренең эшчәнлеген җайга сала, әлеге сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (эш итмәүләренә) карата белдерелгән шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

участок сайлау комиссияләренең адресларын һәм телефон номерларын халыкка җиткерә;

сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен бирелгән акчаларга хуҗа була һәм аларны участок сайлау комиссияләренә бүлеп бирә;

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе белән берлектә тиешле территориядә Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларның барысы өчен дә сайлау алды эшчәнлегендә бертигез хокукый шартлар үтәлешен тәэмин итә;

сайлау бюллетеньнәрен һәм башка документларны участок сайлау комиссияләренә җибәрүне оештыра;

сайлау участокларында тавыш бирүне уздырганда участок сайлау комиссияләренә оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

тиешле территориядә Татарстан Республикасы Президентын сайлаганда тавыш бирү йомгакларын билгели, алар турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итә һәм тавыш бирү йомгакларын хакындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыра;

сайлауларны әзерләү һәм уздыру белән бәйле документларны архивка яисә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыруны оештыра;

кабат тавыш бирүне һәм кабат сайлауларны уздыруны тәэмин итә;

участок сайлау комиссияләрен биналар, транспорт һәм элемтә белән тәэмин итүне тикшереп тора һәм сайлауларны матди-техник тәэмин итүнең башка мәсьәләләрен карый;

әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен бирелгән акчаларның тотылышы турындагы хисапны раслаганнан соң территория сайлау комиссиясенең вәкаләтләр чоры тәмамлана.

16 статья. Участок сайлау комиссиясенең вәкаләтләре

Участок сайлау комиссиясе:

участок сайлау комиссиясенең урнашкан җире һәм эш вакыты турында, шулай ук тавыш бирү көне һәм урыны турында халыкка хәбәр итә;

сайлау участогы буенча сайлаучылар исемлекләрен төзи;

сайлаучыларны сайлаучылар исемлекләре белән таныштыра, сайлаучылар исемлегендәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турында сайлаучылардан кергән гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләр кертү хакындагы мәсьәләне хәл итә;

тавыш бирү урыннарының, сайлау әрҗәләренең һәм башка җи-

һазларның әзерлеген тәэмин итә;

сайлау участогы территориясендә сайлау алды үгетләве материалларын урнаштыру кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп тора;

сайлау участогында сайлаулар көнендә тавыш бирүне оештыра;

тавышларны саный, сайлау участогында Татарстан Республикасы Президентын сайлаганда тавыш бирү йомгакларын билгели, аларны тиешле территория комиссиясенә тапшыруны һәм документларны архивка тапшыру өчен әзерләүне тәэмин итә;

әлеге Законны бозу турындагы шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм алар буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләр башкара.

Участок сайлау комиссиясенең вәкаләтләре чоры Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң һәм ул сайлау документларын тиешле сайлау комиссиясенә тапшырганнан соң тәмамлана.

<u>17 статья.</u> Сайлау комиссиясе әгъзасының статусы

Сайлау комиссиясе әгъзасы сайлау комиссиясенең һәр утырышында катнашырга тиеш.

Сайлау комиссиясе составына Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар, аларның ышанычлы затлары, кандидатларның ире яисә хатыны һәм якын туганнары, кандидатларның турыдан-туры буйсынуында булган затлар керә алмый.

Сайлау комиссиясе әгъзасы:

тиешле сайлау комиссиясенең утырышлары хакында алдан ук кисәтелә;

сайлау комиссиясе утырышында чыгыш ясарга, тиешле сайлау комиссиясе вәкаләтләренә караучы мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертергә һәм алар буенча тавыш бирү уздыруны таләп итәргә хаклы;

сайлау комиссиясе утырышында катнашучыларга көн тәртибе нигезендә сораулар бирергә һәм аларның асылы буенча җаваплар алырга хаклы;

тиешле һәм түбәнгерәк сайлау комиссияләренең теләсә нинди документалары һәм материаллары белән танышырга һәм әлеге документларның таныкланган күчермәләрен алырга хаклы.

Сайлау комиссиясе әгъзасы вәкаләтләре чоры узганчы үзен

билгеләп куйган орган карары нигезендә түбәндәге очракларда вазыйфаларыннан азат ителергә мөмкин:

сайлау комиссиясе әгъзасы үз вәкаләтләрен туктату турындагы язмача гариза биргәндә;

даими яшәү өчен Татарстан Республикасыннан читкә күчеп киткәндә;

сайлау комиссиясе әгъзасына карата гаепләүче хөкем карары закон көченә кергәндә;

закон көченә кергән суд карары нигезендә сайлау комиссиясе әгъзасы хезмәткә сәләтсез, өлешчә сәләтсез, кайдалыгы мәгълүм түгел яисә вафат булган дип танылганда.

Сайлауларны әзерләү һәм уздыру чорына төп эшеннән азат ителгән сайлау комиссиясе әгъзасына хезмәт өчен түләү сайлауларны уздыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән башкарыла һәм ул уртача хезмәт хакыннан ким булмаска тиеш. Үз вәкаләтләре чорында ул хакимият (эш бирүче) инициативасы буенча эшеннән азат ителми яисә үз ризалыгыннан гайре бүтән эшкә күчерелә алмый.

Сайлау комиссиясе әгъзасы сайлауларны уздыру чорында тиешле прокурор ризалыгыннан гайре җинаять җаваплылыгына җәлеп ителми яисә хөкем тәртибендә билгеләнүче административ җәза гамәлләренә тартылмый.

<u>18 статья.</u> Сайлау комиссияләре эшчәнлегендә хәбәрдарлык

Сайлау комиссияләренең эшчәнлеге ачык һәм хәбәрдар рәвештә башкарыла. Сайлау комиссияләре утырышларында Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар һәм аларның ышанычлы затлары, сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәренең вәкаләтле вәкилләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хаклы.

Сайлау комиссиясенең карарлары кандидатларны теркәү йомгакларын, аларның биографик белешмәләрен, һәр кандидат буенча тавыш бирү йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен гражданнарга җиткерәләр.

Тавыш бирү көнендә участок сайлау комиссиясенең эше башланган мизгелдән алып сайлау участокларында тавыш бирү йомгаклары турындагы документлар эшләнеп беткәнче Татарстан Респуб-

ликасы Президентын сайлауларда катнашучы һәр кандидат, җәмәгать һәм сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары җибәргән кимендә ике күзәтүче, чит илләрнең (халыкара) күзәтүчеләре, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре булырга хаклы. Чит илләрнең (халыкара) күзәтүчеләре үз эшчәнлекләрен законнар нигезендә гамәлгә ашыралар.

Күзәтүченең вәкаләтләре үаләрен җибәргән кандидат, җәмәгать яисә сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан язма рәвештә таныкланырга тиеш һәм бу документта күзәтүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәгән җире, шулай ук ул җибәрелгән сайлау участогының номеры күрсәтелә. Әлеге документ бары тик паспортын (аны алмаштырырлык шәхес таныклыгын) күрсәткәндә генә дөрес була. Сайлау участогына күзәтүче җибәрү турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Күзәтүче түбәндәгеләргә хаклы:

сәламәтлеге аркасында яисә башка мәгълүм сәбәпләр аркасында тавыш бирү урынына килә алмаучы сайлаучылар тавыш биргәндә карап торырга;

участок сайлау комиссиясенә тәкъдимнәр һәм кисәтүләр белән мөрәҗәгать итәргә;

участок сайлау комиссиясенең гамәлләренә (эш итмәүләренә) карата территория сайлау комиссиясенә шикаять белән мөрәҗәгать итәргә.

Участок сайлау комиссиясенең гамәлләренә тыкшыну рөхсәт ителми. Күзәтүчеләрнең кисәтүләрен һәм тәкъдимнәрен участок сайлау комиссиясенең рәисе карый, ә кирәк чакта участок сайлау комиссиясе утырышында карала.

<u>19 статья.</u> Сайлау комиссияләренең эшчәнлеген оештыру

Сайлау комиссиясенең рәис урынбасары һәм комиссия сәркәтибе тиешле сайлау комиссиясе утырышында сайлана.

Сайлау комиссиясенең утырышында сайлау комиссиясе әгъзаларының кимендә әчтән икесе катнашса, сайлау комиссиясе утырышы тулы вәкаләтле була.

Сайлау комиссияләренең карарларын кабул иткәндә хуплап һәм каршы бирелгән тавышлар саны тигез булса, сайлау комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч санала.

Сайлау комиссияләренең үз вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән карарлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары өчен, шулай ук түбәнгерәк сайлау комиссияләре өчен мәҗбүри.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең рәисен һәм сәркәтибен сайлау турындагы, Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны теркәү хакындагы, сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча, сайлауларның нәтиҗәләрен билгеләү турындагы, сайлауларны узмаган яисә гамәлгә яраксыз дип табу хакындагы, кабат тавыш бирү яисә кабат сайлаулар турындагы Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе карарлары Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе утырышында Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Башка сайлау комиссияләренең сайлау комиссиясе рәисе урынбасарын һәм комиссия сәркәтибен сайлау турындагы, сайлауларны әзерләүне һәм үткәрүне финанс белән тәэмин итү мәсьәләре буенча, тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү хакындагы карарлары шулай ук сайлау комиссияләре әгъзаларының гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

Сайлау комиссияләренең башка мәсьәләләр буенча карарлары сайлау комиссиясенең утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

Сайлау комиссиясе карарына сайлау комиссиясе рәисе һәм сәркәтибе имза сала.

Сайлау комиссиясенең кабул ителгән карары белән килешмәгән сайлау комиссиясе әгъзалары үзләренең махсус фикерләрен язма рәвештә белдерергә хаклы, әлеге фикерне сайлау комиссиясе рәисе югарырак сайлау комиссиясенә - өч көн эчендә, ә сайлауларга өч көн кала һәм сайлаулар көнне кичекмәстән җиткерергә тиеш.

Сайлау комиссиясенең законнарны бозып кабул ителгән карары югарырак сайлау комиссиясе яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш.

Сайлау комиссиясенең утырышлары сайлау комиссиясе рәисе яисә аның кушуы буенча рәис урынбасары тарафыннан чакырыла һәм

уздырыла. Сайлау комиссиясе утырышлары шулай ук сайлау комиссиясе әгъзаларының кимендә өчтән бере таләбе буенча да уздырыла.

Сайлау комиссияләренең утырышларында шикаятьләр (гаризалар) каралганда кызыксынучы якларның вәкилләре дә катнашырга хаклы.

Сайлау комиссиясе рәисе, рәис урынбасары һәм комиссия сәркәтибе, шулай ук сайлау комиссиясе карары нигезендә аның башка әгъзалары да сайлау комиссиясендә штатта торып эшли алалар. Сайлау комиссиясе әгъзаларының хезмәте өчен түләү сайлау комиссиясенә бирелгән бюджет акчалары чикләрендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә башкарыла.

20 статья. Сайлау комиссияләренең эшчәнлекләренә ярдәм итү

Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, шулай ук аларның урындагы затлары сайлау комиссияләренә үз вәкаләтләрен башкарганда, шул исәптән кирәкле биналар, транспорт, элемтә чаралары һәм техник җайланмалар бирүдә ярдәм итәргә, шулай ук белешмәләр һәм материаллар бирергә һәм сайлау комиссияләренең мөрәҗәгатьләренә - унбиш көн эчендә, ә сайлауларга биш көн кала һәм сайлаулар көнне кичекмәстән җавап бирергә тиешләр.

21 статья. Сайлау комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә карата шикаять белдерү

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе карарларына һәм гамәлләренә (эш итмәүләренә) карата Татарстан Республикасының Югары судына шикаять белдерелергә мөмкин.

Башка сайлау комиссияләренең һәм аларның урындагы затларының карарларына һәм гамәлләренә (эш итмәүләренә) карата югарырак сайлау комиссиясенә яисә район (шәһәр) судына шикаять белдерелергә мөмкин. Югарырак сайлау комиссияләренә алдан мөрәҗәгать итү судка мөрәҗәгать итүнең мәҗбүри шарты булмый. Та-

тарстан Республикасы Югары судының карары катгый була.

Судка кергән шикаятьләр (гаризалар) әлеге Законда билгеләнгән вакытларда карала.

Югарырак сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар) буенча карарлар сайлау комиссиясенә килеп кергән мизгелдән соң - биш көн эчендә, ә сайлауларга биш көн кала һәм сайлаулар көнне кичекмәстән кабул ителә. Әгәр дә шикаятьләрдәге (гаризалардагы) фактларны өстәмә тикшерү таләп ителсә, алар буенча карарлар ун көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

Югарырак сайлау комиссиясе, түбәнгерәк сайлау комиссиясенең карарын юкка чыгарып, шикаятьнең (гаризаның) асылы буенча мөстәкыйль карар кабул итәргә хаклы.

<u>22 статья.</u> Сайлау участокларын төзү

Татарстан Республикасы Президентын сайлаганда тавыш бирү һәм тавышларны санау өчен сайлау участоклары төзелә.

Сайлау участоклары, җирле һәм башка шартларны исәпкә алып, сайлаучыларга мөмкин кадәр уңай шартлар тудыру йөзеннән, тиешле территория сайлау комиссиясе белән килешенеп, сайлауларга 75 көннән дә соңга калмыйча, җирле хакимият башлыгы карары нигезендә төзелә.

Сайлау участоклары түбәндәге таләпләрне исәпкә алып төзелә:

һәр сайлау участогында 100 дән алып 3000 гә кадәр сайлаучы булу;

районнарның, республика буйсынуындагы шәһәрләрнең, шәһәрләрдәге районнарның гамәлдәге чикләрен бозмау.

Шифаханәләрдә, профилактирийларда, ял йортларында, сырхауханәләрдә, башка ятып дәвалану - профилакторий учреждениеләрендә һәм сайлаучыларның башка вакытлыча тору урыннарында сайлау участоклары - әлеге статьяның икенче өлешендә билгеләнгән вакытта, ә гадәттән тыш очракларда сайлауларга биш көннән дә соңга калмыйча төзелергә мөмкин.

Сайлау участокларының исемлекләре, номерлары, чикләре, адреслары һәм телефон номерлары күрсәтелгән килеш, алар төзелгәннән соң өч көн эчендә җирле матбугатта бастырып чыгарыла.

23 статья. Сайлаучылар исемлеге һәм аны төзү тәртибе

Сайлаучылар исемлеген билгеләнгән тәртиптә җирле хакимият һәм җирле үзидарә тарафыннан бирелгән белешмәләр нигезендә участок сайлау комиссиясе төзи.

Сайлаучылар исемлеге һәр сайлау участогы буенча алфавит тәртибендә яисә тавыш бирүне оештыру өчен җайлы бүтән тәртиптә (торак пунктлары, урамнар, йортлар һәм башка шартлар буенча) төзелә. Исемлектә сайлаучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшькә җиткәннәренең - өстәмә рәвештә туган көне һәм ае) һәм яшәү урынының адресы күрсәтелә.

Хәрби частьтәге хәрби хезмәткәр сайлаучыларның, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең гаилә әгъзаларының һәм башка сайлаучыларның исемлеге, әгәр алар хәрби часть урнашкан районда яшәсәләр, хәрби часть командиры биргән белешмәләр нигезендә төзелә.

Хәрби частьтән читтә яшәүче хәрби хезмәткәрләр яшәү урыны буенча төзелгән сайлаучылар исемлегенә гомуми нигезләрдә кертеләләр.

Сайлаулар көнне шифаханәләрдә, профилакторийларда, ял йортларында, сырхауханәләрдә, башка ятып дәвалану учреждениеләрендә һәм вакытлыча бүтән урыннарда булачак сайлаучылар исемлекләре әлеге учреждениеләрнең җитәкчеләре биргән белешмәләр нигезендә төзелә.

Сайлаучылар исемлеге Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвештә ике нөсхәдә төзелә һәм аңа участок сайлау комиссиясе рәисе, аның сәркәтибе имза сала. Сайлаучылар исемлегенең бер нөсхәсе участок сайлау комиссиясендә кала, ә икенче нөсхәсе, сайлауларга 16 көннән дә соңга калмыйча, тиешле территория сайлау комиссиясенә тапшырыла.

24 статья. Гражданнарны сайлаучылар исемлекләренә кертү тәртибе

Сайлаучылар исемлекләренә әлеге Законның 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасының актив сайлау хокукына ия барлык гражданнары кертелә.

156



Гражданның әлеге сайлау участогы территориясендә даими яисә вакытлыча яшәү факты аны конкрет сайлау участогындагы сайлаучылар исемлегенә кертү өчен нигез була.

Сайлаучы бары тик бер генә сайлау участогындагы сайлаучылар исемлегенә кертелергә мөмкин.

Сайлаулар көнне шифаханәләрдә, профилакторийларда, ял йортларында, сырхауханәләрдә, башка ятып дәвалану-профилакторий учреждениеләрендә һәм сайлаучыларның бүтән вакытлыча тору урыннарында булган сайлаучылар үзләренең тору урыны буенча сайлаучылар исемлегенә кертеләләр.

Кендез укучы һәм тулай торакларда яшәүче студентлар һәм аспирантлар тулай торак урнашкан сайлау участогындагы сайлаучылар исемлегенә кертеләләр.

Сайлаучылар исемлеген гомуми танышу өчен тапшырганнан соң сайлау участогы территориясенә килеп урнашкан сайлаучылар, шулай ук теге яисә бу сәбәпләр аркасында сайлаучылар исемлегенә кертелми калган сайлаучылар аларның шәхесләрен таныклаучы һәм аларның әлеге сайлау участогы территориясендә яшәвен раслаучы документлар нигезендә сайлаучылар исемлегенә участок сайлау комиссиясе тарафыннан өстәмә рәвештә кертеләләр.

<u>25 статья.</u> Сайлаучылар исемлекләре белән сайлаучыларны таныштыру

Сайлаучылар исемлекләре, сайлауларга 20 көннән дә соңга калмыйча, гомуми танышу өчен тәкъдим ителә.

Һәр гражданга үзенең сайлаучылар исемлегенә кертелмәве хакында, шулай ук сайлаучылар исемлегендәге теләсә нинди хата яисә төгәлсезлек турында участок сайлау комиссиясенә хәбәр итү хокукы бирелә.

Участок сайлау комиссиясе гаризаны тикшерергә һәм хатаны яисә төгәлсезлекне төзәтергә йә, 24 сәгатьтән дә соңга калмыйча, гаризаның кире кагылу сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәр итүчегә язма рәвештә җавап бирергә тиеш. Участок сайлау комиссиясенең карарына карата югарырак сайлау комиссиясенә яисә судка шикаять белдерелергә мөмкин, ә алар исә шикаятьне (гаризаны) - өч көн эчендә, ә сайлауларга өч көн кала һәм сайлаулар көнне кичекмәстән карарга тиеш.

Сайлаучыларның тавышларын санау башланганнан соң сайлаучылар исемлекләренә үзгәрешләр кертү тыела.

## Ш бүлек. Сайлау берләшмәләре

26 статья. Сайлау берләшмәсе төшенчәсе

Законнарда билгеләнгән тәртиптә төзелгән, уставында кандидатлар тәкъдим итү юлы белән дәүләт хакимияте органнарына сайлауларда катнашуы күз алдында тотылган һәм, сайлаулар көнен игълан иткәнчегә кадәр алты айдан соңга калмыйча, Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгы тарафыннан теркәлгән республика җәмәгать берләшмәсе сайлау берләшмәсе була.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздыру чорына төзелүче сайлау блоклары да сайлау берләшмәсе хокукларына ия булалар.

27 статья. Сайлау блоклары

Әлеге Законның 26 статьясындагы беренче өлеше нигезендә сайлау берләшмәсе дип саналучы кимендә ике җәмәгать берләшмәсеннән сайлау блоклары төзелергә мөмкин.

Әгәр җәмәгать берләшмәсе сайлау блогы составына керсә, ул сайлаулар үткәрү чорына мөстәкыйль сайлау берләшмәсе сыйфатында эш итә алмый яисә башка сайлау блогына керә алмый.

Сайлау блогына керү турындагы карар сайлау берләшмәсенең корылтаенда (конференциясендә) кабул ителә.

Сайлау блокларын Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе терки. Җәмәгать берләшмәләренең сайлау блогына керүләре хакындагы карарлары, әлеге җәмәгать берләшмәләренең сайлау блогы төзү хакындагы, аларның вәкаләтле вәкилләре имза салган уртак карары белән бергә җәмәгать берләшмәләре корылтайларының (конференцияләренең) беркетмәләре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылганнан соң биш көннән дә соңг калмыйча, сайлау блогын теркәү уздырыла.

158



28 статья. Сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының һәм сайлаучыларның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкилләре

Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы, сайлаучыларның инициатив төркеме Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашуларына бәйле барлык мәсьәләләр буенча, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча да үзләре исеменнән эш йөртүче һәм әлеге Закон нигезендә вәкаләт тапшырылучы вәкилләрен билгеләп куялар.

29 статья. Сайлау берләшмәләренең, сайлау блокларының һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәренең Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда катнашулары

Сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәре Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә бертигез шартларда катнашалар.

IV бүлек. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны тәкъдим итү һәм теркәү

30 статья. Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны тәкъдим итү

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат сайлау берләшмәсе корылтаенда (конференциясендә) тәкъдим ителә.

Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы Татарстан Республикасы Президенты урынына бары тик бер генә кандидат тәкъдим итәргә хаклы. Корылтайга (конференциягә) сайланган делегатларның яртысыннан артыграгы кандидатны яклап тавыш бирсә, ул тәкъдим ителгән дип санала.

Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләре Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат тәкъдим итү турындагы карары белән бергә әлеге җәмәгать берләшмәсе корылтаеның (кон-

ференциясенең) беркетмәсен Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыра. Кандидатны тәкъдим итү турындагы карарда аның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, эш урыны, биләгән урыны (шөгыленең төре) һәм яшәү урыны күрсәтелергә тиеш.

Әлеге документлар белән бер үк вакытта җәмәгать берләшмәсенең уставы күчермәсе, сайлау берләшмәсенең һәр вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелгән килеш, аларның составы, шулай ук сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкилләренә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән таныклама тапшырыла.

Сайлау блогының вәкаләтле вәкилләре әлеге статьяның дүртенче һәм бишенче өлешләрендә күрсәтелгән документлар белән бер үк вакытта җәмәгать берләшмәләренең сайлау блогына керүләре хакындагы карарлары һәм җәмәгать берләшмәләренең сайлау блогы төзү хакындагы, вәкаләтле вәкилләре имза салган уртак карары белән бергә шушы җәмәгать берләшмәләре корылтайларының (конференцияләренең) беркетмәләрен Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыралар.

<u>31 статья.</u> Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны сайлаучыларның турыдан-туры тәкъдим итүләре

Татарстан Республикасының актив сайлау хокукына ия булган һәр гражданы Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат тәкъдим итү өчен кимендә 100 кешедән торган сайлаучыларның инициатив төркемен төзергә мөмкин.

Сайлаучыларның инициатив төркеме Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә төркемне теркәттерү турындагы язма үтенеч белән мөрәҗәгать итә. Үтенечкә сайлаучыларның инициатив төркеме җыелышының Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат тәкъдим итү турындагы, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләрен билгеләп кую хакындагы беркетмәсе һәм билгеләнгән тәртиптә алар исеменә тутырылган таныклама өстәлеп бирелә. Җыелышта сайлаучыларның инициатив төркеменең яртысыннан артыграгы кандидатны яклап тавыш бирсә, ул тәкъдим ителгән дип санала.

Сайлаучыларның инициатив төркеме утенечендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, эш урыны, биләгән урыны (шөгыленең төре) һәм яшәү урыны;

сайлаучыларның инициатив төркеме әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының (аны алмаштырырлык шәхес таныклыгының) сериясе һәм номеры.

32 статья. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны яклап имзалар җыю

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны тәкъдим итү турындагы карарлар әлеге Законның 3 статьясы нигезендә сайлау хокукына ия булган кимендә 50 мең Татарстан Республикасы гражданының имзаларын җыю юлы белән якланырга тиеш. Бу очракта бер районга, республика буйсынуындагы бер шәһәргә, шәһәрдәге бер районга таләп ителүче имзалар санының җиде проценттан артык булмаган өлеше туры килергә тиеш.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе үзенә тапшырылган документларның әлеге Закон таләпләренә туры килүен ачыклагач, алар тапшырылганнан соң ике көн эчендә вәкаләтле вәкилләрне теркәү турында карар кабул итәргә һәм аларга теркәлү таныклыклары бирергә тиеш.

Теркәүдән баш тарткан очракта вәкаләтле вәкилләргә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең дәлилләнгән карары тапшырыла. Теркәүдән баш тарту хакында Татарстан Республикасының Югары судына шикаять белдерелергә мөмкин, ә Югары суд исә бу шикаятьне өч көннән дә соңга калмыйча карарга тиеш.

Теркәлү таныклыклары алганнан соң вәкаләтле вәкилләр Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны яклап сайлаучыларның имзаларын җыярга хаклы. Теркәлү таныклыклары алганчы имзалар җыю рөхсәт ителми.

Имза кәгазьләре әлеге Законга өстәлгән 1 һәм 2 кушымталарда күрсәтелгән рәвештә әзерләнәләр.

Кандидатны яклап имзалар җыйганда һәр имза кәгазендә кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, эш уры-

ны, билгән урыны (шөгыленең төре) һәм яшәү урыны күрсәтелә.

Сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тәкъдим иткән кандидатны яклап имзалар җыйганда, имза кәгазендә күрсәтелгән белешмәләрдән тыш, кандидатның кайсы сайлау берләшмәсенә, сайлау блогына каравы да күрсәтелә.

Сайлаучылар төрле сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан яисә сайлаучыларның инициатив төркемнәреннән тәкъдим ителүче кандидатларны яклап имза салырга хаклы, әмма бу гамәл бер генә мәртәбә һәм бары тик бер генә кандидатны яклап башкарыла. Бу очракта үзләренең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшькә житкәннәр - өстәмә рәвештә туган көннәре һәм айлары), яшәү урынының адресы, паспортының яисә аны алмаштырырлык шәхес таныклыгының сериясе һәм номеры, шулай ук имза салынган көн күрсәтелә.

Имза кәгазенә имзалар җыючы зат һәм вәкаләтле вәкил фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урынын, паспортының яисә аны алмаштырырлык шәхес таныклыгының сериясен һәм номерын күрсәткән килеш имза салалар. Һәр имза кәгазендә сайлаучыларның имзаларын җыю үткәрелүче Татарстан Республикасы районының, шәһәренең, шәһәрдәге районының исеме күрсәтелергә тиеш.

Сайлаучыларның имзаларын җыю эш (шул исәптән хезмәт коллективларында), хезмәт, уку, яшәү урыннарында, сайлау алды гамәлләре вакытында, шулай ук үгетләү һәм имзалар җыю тыелмаган башка урыннарда уздырыла. Бу чакта имзалар җыючы зат тарафыннан сайлаучыны нинди дә булса юллар белән имза салырга мәҗбүр итәргә һәм сатып алырга тырышу тыела.

Милек рәвешләренә карамастан, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең һәм оешмаларның хакимиятләре һәм хезмәт коллективлары кандидатларны яклап имзалар җыю өчен бертигез шартлар тудырырга ярдәм итәргә тиеш.

Имзалар җыю тәмамланганнан соң сайлау берләшмәсенең, сайлау блогының һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәренең вәкаләтле вәкилләре һәр район, һәр шәһәр һәм шәһәрдәге һәр район буенча сайлаучыларның имзаларын, шулай ук имзаларның гомуми санын исәплап чыгаралар.

Имзалар җыю уздырылган район, шәһәр, шәһәрдәге район буенча брошюра рәвешендә тупланган һәм номерлар сугылган имза кәгазьләрен, йомгаклау беркетмәсен, кандидатның Татарстан Республикасы Президенты урынына чыгарга ризалыгы хакындагы Та-

тарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә язылган гаризасын һәм кандидатның сайлауларга кадәрге соңгы ике елдагы керемнәре турындагы декларациясен вәкаләтле вәкилләр законда билгеләнгән рәвештә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә, сайлауларга 45 көннән дә соңга калмыйча, әмма соңгы көнне 18 сәгатькә кадәр генә тапшыралар. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе әлеге вәкаләтле вәкилләргә документларын алуы турында язма таныклама бирә.

Татарстан Республикасы Президентын вакытыннан алда сайлаулар яисә кабат сайлаулар уздырылган очракта әлеге статьяның беренче өлеше нигезендә җыелырга тиешле имзалар саны яртылаш кими.

33 статья. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны теркәү

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе документлар кабул иткән көннән башлап 10 көн дәвамында әлеге Законның 3 статьясы таләпләре үтәлешен һәм Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар тәкъдим итү тәртибенең әлеге Закон таләпләренә туры килүен тикшерә һәм, сайлауларга 35 көннән дә соңга калмыйча, кандидатларны теркәү турында карар яисә кандидатларны теркәүдән баш тарту хакында дәлилләнгән карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан имза кәгазьләренең һәм башка документларның дөреслеге тикшерелгәндә, тиешле сайлау берләшмәләреннән, сайлау блокларыннан һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәреннән вәкаләтле вәкилләр, шулай ук Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар катнашырга хаклы.

Имза кәгазьләрендәге белешмәләрнең дөреслегенә яисә сайлаучылар имзаларының дөреслегенә шик туганда, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе имза кәгазьләрен тикшерүне оештыра.

Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон бозылган очракта гына Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны теркәүдән баш тартырга мөмкин. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе Та-

тарстан Республикасы Президенты урынына кандидатны теркәүдән баш тарту турында дәлилләнгән карар чыгара. Күрсәтелгән карар Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат итеп теркәлмәгән затка җиткерелә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең кандидатны теркәү турындагы яисә кандидатны теркәүдән баш тарту хакындагы карарына карата Татарстан Республикасы Югары судына шикаять белдерелергә мөмкин. Шикаять өч көн эчендә каралырга тиеш. Татарстан Республикасы Югары судының аны карау нәтиҗәләре буенча чыгарылган карары катгый була.

Теркәлгән һәр кандидатка теркәлүнең көне һәм вакыты күрсәтелгән теркәлү таныклыгы бирелә. Кандидатларны теркәгәннән соң ике тәүлек эчендә теркәлгән кандидатлар турында белешмәләр массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

Әгәр теркәгәннән соң һәм сайлаулар көненә кадәр Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларның берсе дә калмаса, өстәмә рәвештә яңа кандидатлар тәкъдим итү һәм тиешле сайлау гамәлләрен тормышка ашыру өчен сайлаулар Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан 75 көнгә кичектерелә.

## V бүлек. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның статусы

### 34 статья. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар хокукларының һәм бурычларының бертигез булуы

Татарстан Республикасы Президенты урынына теркәлгән барлык кандидатлар да бертигез хокукларга һәм бурычларга ия.

### 35 статья. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның хокуклары һәм бурычлары

Теркәлгәннән соң кандидатлар теркәлгән көннән башлап сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр шәхси

гариәалары буенча эштән, хәрби хезмәттән һәм хәрби җыелулар азат ителергә мөмкин. Шушы дәвердә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән кандидатка аның уртача айлык керемнәре күләмендә акчалата компенсация түли, ул сайлаулар көненә Татарстан Республикасы законнары тарафыннан билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 10 минималь күләменнән артмаска тиеш.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат теркәлгән көннән башлап сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр хакимият (эш бирүче) инициативасы белән эштән азат ителергә, аның ризалыгыннан башка эшкә яисә хезмәт урынына күчерелергә , шул исәптән бүтән җиргә эшкә дә күчерелергә, шулай ук командировкага җибәрелергә, хәрби хезмәткә һәм хәрби җыелуларга алынырга тиеш түгел. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның сайлауларда катнашкан вакыты теркәлгәнгә кадәр эшләгән белгечлеге буенча хезмәт стажына кертеп санала.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат теркәлгән көннән башлап сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә юл йөргәндә җәмәгать транспортының барлык төреннән (таксидан һәм заказ рейсларыннан гайре) түләүсез файдаланырга хаклы. Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә юл чыгымнарын сайлауларны әзерләү һәм уздыру өчен бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе түли.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат сайлаулар көненә кадәр теләсә кайчан үз кандидатурасын кире алырга хаклы. Әгәр кандидатураны кире алу җитди сәбәпләр аркасында булмаса, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе сайлаулар уздыру буенча тоткан чыгымнарының тиешле өлешен, сайлау алды үгетләвенә бүлеп бирелгән акчаларны да кертеп, кандидаттан түләттерә.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның 20 гә кадәр ышанычлы заты булырга мөмкин, алар кандидатның һәм ышанычлы зат булырга ризалык белдергән гражданның яма гариәалары нигезендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар бу-

енча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан теркәләләр. Ышанычлы затлар Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясеннән таныклык алалар һәм кандидатның сайлануына ярдәм итә торган үгетләүне һәм бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашыралар. Әлеге статьяның икенче өлешендә күрсәтелгән чорга хакимият (эш бирүчеләр) ышанычлы затларга аларның үтенече буенча түләүсез ял бирергә тиеш. Ышанычлы затларын билгеләгән кандидатлар, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итеп, аларны теләсә кайсы вакытта кире чакыртып алырга хаклы, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе бу ышанычлы затларга бирелгән таныклыкларны юкка чыгара.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат Татарстан Республикасы Прокуроры ризалыгыннан гайре җинаять җаваплылыгына җәлеп ителми, кулга алынмый яисә хөкем итү тәртибендә билгеләнә торган административ җәза гамәлләренә тартылмый. Татарстан Республикасы Прокуроры мондый ризалык бирүе хакында кичекмәстән Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә.

Дәүләт хезмәтендәге яисә массакүләм мәгълүмат чараларында эшләүче Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның хезмәт урынындагы өстенлекләрдән файдаланырга хакы юк.

Кандидат тарафыннан әлеге Закон таләпләре бозылганда, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе аны язма рәвештә кисәтә, ә кабат бозылганда, әлеге кандидатны теркәү хакындагы карарны гамәлдән чыгарырга мөмкин, бу хакта сайлаучыларга һәм кандидатларга җиткерелә.

## VI бүлек. Сайлау алды үгетләве

### 36 статья. Сайлау алды үгетләвендә катнашу хокукы һәм аны алып бару вакытлары

Татарстан Республикасы гражданнары, сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары, хезмәт коллективлары, сайлаучыларның инициатив төркемнәре, кандидатлар үзләре Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны яклап яисә аларга каршы

үгетләүне тоткарлыксыз алып барырга хаклы.

Сайлау комиссияләре әгъзаларына сайлау алды үгетләве алып бару, нинди дә булса үгетләү материаллары тарату, шулай ук сайлау комиссиясе урнашкан биналарда үгетләү алып бару тыела.

Сайлау алды үгетләве кандидатны теркәгән көннән башлана һәм сайлауларга кадәр бер көн кала җирле вакыт белән 0 сәгатьтә тәмамлана. Сайлау комиссияләре урнашкан биналардан читтә элегрәк эленгән басма үгетләү материаллары шул ук урыннарда саклана.

Сайлау алды үгетләве түбәндәгечә алып барылырга мөмкин:

массакүләм мәгълүмат чаралары аша;

сайлаучылар белән сайлау алды җыелышлары һәм очрашулар,сайлау алды фикер алышулары һәм әңгәмәләр, митинглар, урам хәрәкәтләре, демонстрацияләр һәм башка сайлау алды гамәлләре уздыру юлы белән;

басма, аудиовизуаль һәм башка төр сайлау алды материалларын бастырып чыгару һәм тарату юлы белән;

закон тарафыннан тыелмаган башка рәвешләрдә.

Барлык үгетләүче басма материалларда аларны чыгару өчен җаваплы оешмалар һәм затлар турында мәгълүматлар булырга тиеш.Үгетләү материалларын исемсез /аноним/ тарату тыела. Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларны мәсхәрәләүче,аларның намусларына һәм абруйларына кагылучы уйдырмалар тарату рөхсәт ителми.

Сайлаучыларга бушлай яисә өстенлекле шартларда товарлар өләшү һәм хезмәт күрсәтүләр /мәгълүмати хезмәт күрсәтүләрдән гайре) юлы белән, кыйммәтле кәгазьләр, шулай ук акча бирү юлы белән сайлау алды үгетләвен алып бару тыела.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар, аларның ышанычлы затлары яисә сайлау комиссияләре әгъзалары булган журналистларга, массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең урындагы затларына, мәгълүмати теле-һәм радиопрограммалар /тапшырулар/ алып бару, шушы массакүләм мәгълүмат чаралары аша сайлауларны яктыртуда катнашу тыела.

Сайлау алды программаларында, сайлау алды үгетләү материалларында һәм җыелышлардагы, митинглардагы, массакүләм мәгълүмат чараларындагы чыгышларда конституциячел төзелеш нигезләрен көч кулланып үзгәртүгә өндәмәләр булмаска тиеш.Җәмгыяви, раса-

чыл, милли, дини яисә тел өстенлекләрен күздә тоткан үгетләү һәм пропаганда алып бару, җәмгыяви, расачыл, милли яисә дини каршылыклар тудыручы белешмәләр һәм материаллар чыгару һәм тарату тыела.

Сайлау комиссияләре сайлау алды үгетләвен алып баруның билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп торалар. Хокукка каршы чыгышлар ясау яисә хокукка каршы үгетләү материаллары тарату турында хәбәр алганнан соң, алар хокукка каршы алып барыла торган үгетләү эшчәнлеген туктату буенча чаралар күрәләр һәм хокукка каршы булган үгетләү эшчәнлеген туктату хакындагы тәкъдимнәр белән хокук саклау органнарына мөрәҗәгать итәргә хаклы, күрсәтелгән тәкъдимнәр - өч көн эчендә, ә сайлауларга кадәр өч көн кала кичекмәстән каралырга тиеш.

Теләсә нинди бинада, йортта, корылмада һәм башка объектта, аларның милекчеләре һәм хуҗалары рөхсәте белән, үгетләүче һәм басма материаллар эленергә мөмкин. Сайлау комиссияләре урнашкан биналарда һәм тавыш бирү өчен билгеләнгән урыннарда, шулай ук территория сайлау комиссияләре тарафыннан исемнәре билгеләнә торган һәм тарихи, мәдәни яисә архитектура әһәмиятенә ия булган ядкярләргә, обелискларга, биналарга, йортларга үгетләүче басма материаллар элү тыела.

37 статья. Радио һәм телевидение аша сайлау алды үгетләве

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларга тиешле бюджет исәбеннән финансланучы телерадиокомпанияләр каналларында бертигез шартларда эфир вакыты бирелә.

Кандидатларга, сайлау берләшмәләренә, сайлау блокларына һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәренә дәүләт телерадиокомпанияләре каналларында эфир вакыты бирү тәртибе турындагы күрсәтмә, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең үтәлешен тәэмин итүче дәүләт органнары катнашында, кандидатларның, сайлау берләшмәләренең һәм сайлау блокларының һәм сайлаучыларның инициатив төркемнәренең тәкъдимнәрен һичшиксез исәптә тотып, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан бастырып чыгарыла.

## VП бүлек. Сайлауларны финанслау

**38 статья.** Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны финанс белән тәэмин итү

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны әзерләү һәм уздыру буенча сайлау комиссияләренең чыгымнары, шулай ук сайлау комиссияләренең эшчәнлеген тәэмин итү буенча чыгымнар аларның вәкаләтләр чоры дәвамында Татарстан Республикасының республика бюджеты акчалары исәбеннән түләнә, тиешле чыгымнар бюджетка аерым юл рәвешендә кертелә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларны уздыру өчен республика бюджетында каралган акчалар сайлаулар көнен билгеләгәннән соң ун көн эчендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе карамагына тапшырыла һәм ул аны сайлау комиссияләренә бүлеп бирә.

Сайлау комиссияләренә акча күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән берлектә, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

Сайлау комиссияләренең рәисләре акчага хуҗа булалар һәм сайлау комиссияләренең финанс мәсьәләләре хакындагы карарларына финанс документларының туры килү-килмәве буенча җаваплы булалар. Файдаланылмаган бюджет акчалары, сайлаулар узгач, әлеге статьяның беренче өлешендә каралган максатларда куллану өчен сайлау комиссияләренең махсус исәпләрендә кала.

**39 статья.** Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатның сайлау фонды

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат сайлау алды үгетләвен финанслау өчен үзенең сайлау фондын төзи ала. Сайлау фонды акчалары Россия Федерациясе Саклык банкының "Татарстан" банкы бүлекчәсендәге вакытлы махсус исәбендә саклануга тиеш. Сайлау фонды акчаларын күрсәтелгән максатларда тоту хокукы бары тик шушы фондны төзегән кандидатка гына бирелә.

Россия Федерациясе Саклык банкының "Татарстан" банкы бү-

лекчәләре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең язмача мәгълүматы нигезендә кандидатларга сайлау фондлары төзү өчен вакытлы махсус исәпләр ача. Күрсәтелгән исәпләр буенча процентлар өстәлми һәм түләнми.

Сайлау фондлары түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

кандидатка Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан сайлау алды үгетләве өчен бирелгәнә акчалар;

кандидатның үз акчалары;

кандидатны тәкъдим иткән сайлау берләшмәсе, сайлау блогы, сайлаучыларның инициатив төркеме тарафыннан аңа бүлеп бирелгән акчалар;

физик затларның ирекле иганәләре.

хокукый затларның ирекле иганәләре.

Кандидатның сайлау фонды акчалары исәбеннән чыгымнарының иң чик суммасы сайлаулар көненә Татарстан Республикасында билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең 10 мең минималь күләменнән артмаска тиеш.

Сайлау фондларына түбәндәгеләрдән иганә алу рөхсәт ителми:

чит ил дәүләтләреннән, оешмаларыннан һәм гражданнарыннан;

гражданлыгы булмаган затлардан;

чит ил катнашындагы Россия хокукый затыннан, әгәр чит ил капиталының өлеше аларның устав капиталында 30 проценттан артып китсә;

халыкара оешмалардан һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләрдән;

җирле үзидарә органнарынннан, дәүләт һәм коммуналь предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан;

хәрби частьләрдән, хәрби учреждениеләрдән һәм оешмалардан;

җәмгыяте хәйрия оешмаларыннан һәм дини берләшмәләрдән.

Банклар кандидатларның махсус вакытлы исәпләренә акчалар кертү турында алар кергәннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә белешмәләр бирәләр.

Әгәр кандидатларның сайлау фондларына иганәләр кертергә хокукы булмаган физик яисә хокукый затлардан ирекле иганәләр

кергән булса яки алар әлеге статьяда каралган күләмнәрдән артыграк суммада кергән булса, ирекле иганәләр кандидатлар тарафыннан, сәбәпләре күрсәтелгән килеш, иганәчеләрнең үзләренә тулысынча яисә билгеләнгән күләмнәрдән артыграк кертелгән өлеше кайтарып бирелергә тиеш. Исемсез иганәләр дәүләт керемена күчерелә.

Кандидатларның сайлау фондларына кергән акчаларыннан тыш, аларга сайлау алды үгетләве алып бару өчен башка акчалар куллану тыела.

Банклар кандидатларның махсус вакытлы исәпләрендәге акчаларын тотулары турында Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә аның үтенече буенча язма рәвештә мәгълүматлар бирелә.

Әгәр кандидат үзенең сайлау фондына кергән акчалардан тыш, сайлау алды үгетләве алып бару өчен башка акчалар тотса, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны теркәү турындагы карарны юкка чыгарырга хаклы. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең кандидатны теркәүне юкка чыгару турындагы карарына карата Татарстан Республикасы Югары судына шикаять белдерелергә мөмкин, мондый шикаять Югары суд тарафыннан биш көн эчендә карала, ә сайлауларга биш көн кала кичекмәстән карала.

Кандидатларның сайлау фондларын тәзү өчен ачылган махсус вакытлы исәпләре буенча башкарылучы барлык финанс гамәлләре сайлаулар көнендә туктатыла. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе сайлаулар көненә кадәр тотылган чыгымнарны түләү буенча финанс гамәлләрен башкару вакытын кандидатның үтенече нигезендә озайта ала.

<u>40 статья.</u> Акчаларны исәпкә алу тәртибе һәм финанс буенча хисап бирү

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларга әзерләнү һәм аларны уздыру өчен бүлеп бирелгән бюджет акчаларының, кандидатларның сайлау фондлары акчаларының керүен һәм аларны тотуны исәпкә алу тәртибе, шулай ук сайлауларга әзерләнү һәм аларны уздыру учен бүлеп бирелгән акчаларның керүе һәм аларны

тоту турында сайлау комиссияләренең финанс хисабы рәвешләре, кандидатларның финанс хисабы рәвешләре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.

Кандидатлар, сайлау нәтиҗәләре басылып чыкканнан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә финанс хисабы бирәләр. Күрсәтелгән финанс хисапларының күчермәләре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларына бирелә.

Участок сайлау комиссияләре, сайлау нәтиҗәләре басылып чыкканнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләренә финанс хисаплары бирәләр.

Территория сайлау комиссияләре, сайлау нәтиҗәләре басылып чыккан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә финанс хисаплары тапшыралар.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе, сайлауларның гомуми нәтиҗәләре рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң өч айдан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына республика бюджеты акчаларын тоту турында финанс хисабы бирә.

<u>41 статья.</u> Сайлау фондларының тотылмый калган акчалары турында

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат, сайлаулардан соң 30 көннән дә соңга калмыйча, сайлау фондының тотылмый калган акчаларын Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан бүлеп бирелгән акчага тәңгәл күләмдә Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе исәбенә күчерәләр. Тотылмый калган бюджет акчалары әлеге вакыт узганнан соң Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча Россия Федерациясе Саклык банкының "Татарстан" банкы бүлекчәләре тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе исәбенә бәхәссез рәвештә күчерелә.

Кандидатларның исәпләрендә калган акчалар кертелгән акчаларга тәңгәл күләмнәрдә кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе рәхсәте белән сайлау фондларына иганәләр кертүче оешмаларның һәм затларның агымдагы исәбенә сайлаулар узгач күчерелә.

42 статья. Тикшерү-ревизия хезмәте

Сайлауларга әзерләнү һәм аларны уздыру өчен сайлау комиссияләренә бирелгән акчаларның максатчыл тотылышын тикшереп тору өчен, шулай ук акчаларның керү чыганакларын, сайлау фондлары акчаларын исәпкә алуның дөреслеген һәм Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар тарафыннан аларның дөрес тотылышын тикшереп тору өчен, Татарстан Республикасы дәүләт органнары белгечләрен дә җәлеп итеп, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе каршында тикшерү-ревизия хезмәте төзелә.

VIII бүлек. Тавыш бирүне һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен ачыклау

43 статья. Тавыш бирү бинасы

Тавыш бирү бинасы тиешле җирле хакимият башлыгы тарафыннан участок сайлау комиссиясе карамагына бушлай бирелә.

Тавыш бирү бинасында яшерен тавыш бирү өчен кирәк санда кабиналар яисә бүлмәләр булырга, сайлау бюллетеньнәре бирү урыннары билгеләнергә тиеш. Яшерен тавыш бирү кабиналарына яисә бүлмәләренә өстәлләр һәм язу әсбаплары куела. Карандашлар куллану рөхсәт ителми.

Тавыш бирү өчен сайлау әрҗәләре тавыш бирүчеләр аңа якынлашканда яшерен тавыш бирү кабиналары яисә бүлмәләре аша чыгарлык итеп куелалар.

Тавыш бирүче тарафыннан тавыш бирү кабинасында яисә бүлмәсендә сайлау бюллетене тутырылудан гайре, тавыш бирү барышы тулысынча участок сайлау комиссиясе күз алдында булырга тиеш.

Тавыш бирү бинасында яисә аның каршында ук участок сайлау комиссиясе стенд төзи, анда тутырылган сайлау бюллетененең үр-

нәге һәм Татарстан Республикасы Президенты урынына чыгучы барлык кандидатлар турында мәгълүмати материаллар эленә, аларда үгетләү өндәмәләре булмаска тиеш. Стендтагы тутырылган сайлау бюллетене үрнәгендә кандидатларның фамилияләре язылырга тиеш түгел.

Тавыш бирүне оештыру өчен участок сайлау комиссиясе җаваплы була.

44 статья. Сайлау бюллетене

Татарстан Республикасы Президентын сайлау өчен һәр сайлаучы сайлау бюллетене ала. Сайлау бюллетененең үрнәге һәм тексты, сайлауларга 25 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Сайлау бюллетененең тексты аның бер ягына гына язылырга тиеш. Сайлау бюллетеньнәре Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә басыла, шулай ук теге яисә бу сайлау участогына керүче халык куллана торган телләрдә дә басылырга мөмкин.

Сайлау бюллетененә Татарстан Республикасы Президенты урынына теркәлгән теләсә күпме кандидат кертелергә мөмкин, алфавит тәртибендә аларның фамилиләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм алар турында әлеге Законның 30 статьясындагы дүртенче өлешендә яисә 31 статьясындагы өченче өлешендә каралган мәгълүматлар языла. Әгәр кандидат сайлау берләшмәсе, сайлау блогы тарафыннан тәкъдим ителгән булса, аларның исемнәре күрсәтелә, шулай ук кандидатның сайлау берләшмәсенә, сайлау блогына керүче нинди сәяси фиркадән яисә нинди җәмәгать берләшмәсеннән булуы (әгәр андыйлар булса) күрсәтелә. Әгәр кандидат турыдан-туры сайлаучылар тарафыннан тәкъдим ителгән булса, аның нинди фиркагә караган булуы бары тик кандидатның үз теләге буенча гына күрсәтелә.

Һәр сайлау бюллетененьдә аны тутыру тәртибе турында аңлатма язылган булырга тиеш.

Сайлау бюллетеньнәре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмә буенча басыла һәм, сайлауларга 12 көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләренә бирелергә тиеш.

Участок сайлау комиссияләре сайлау бюллетеньнәрен акт (ведомость) буенча, сайлауларга 12 көннән дә соңга калмыйча, территория сайлау комиссияләреннән алалар. Участок сайлау комиссиясе тарафыннан бирелүче сайлау бюллетеньнәренең саны сайлау участогы буенча сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар санының бер процентыннан артмаска тиеш. Сайлау бюллетененең өстәге уң як почмагына участок сайлау комиссиянең ике әгъзасы имза сала, алар участок сайлау комиссиясе мөһере белән раслана. Расланмаган сайлау бюллетеньнәре билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр дип таныла һәм тавышларны санаганда алар исәпкә керми.

Сайлау бюллетеньнәре әзерләнгәннән соң кайбер кандидатлар төшеп калган очракта участок сайлау комиссияләре Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча сайлау бюллетеньнәрендә төшеп калган кандидатлар турындагы мәгълүматларны сызып ташлыйлар.

<u>45 статья.</u> Тавыш бирү тәртибе

Сайлаулар көнендә тавыш бирү җиде сәгатьтән алып егерме бер сәгатькә кадәр үткәрелә. Тавыш бирү вакыты һәм урыны турында участок сайлау комиссияләре, сайлауларга ун көннән дә соңга калмыйча, сайлаучыларга хәбәр итәләр. Кирәк чакта территория сайлау комиссиясе, җирле шартларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, тавыш бирү вакытын үзгәртергә мөмкин.

Сайлауларга кадәр 10 көн кала районнан, шәһәрдән читкә китүче һәм сайлаулар көнендә үзенең сайлаучылар исемлегенә теркәлгән сайлау участогы бинасына кайтып җитү мөмкинлеге булмаган сайлаучы вакытыннан алда тавыш бирә ала. Бу очракта ул территория (сайлауларга кадәр 10-3 көн кала) яисә участок (сайлауларга кадәр 2 көн кала) сайлау комиссиясе бинасында сайлау бюллетене тутыра, мондый чакта яшерен тавыш бирү шарты бозылмаска тиеш. Беренче очракта сайлаучыга бирелүче сайлау бюллетененең өстәге уң як почмагына тиешле территория сайлау комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар шушы комиссия мөһере белән раслана. Тутырылган сайлау бюллетенен сайлаучы конвертка

сала, аны ябыштыра һәм территория яисә участок сайлау комиссиясенең киәү торучы әгъзасына тапшыра. Конвертның ябыштырылган урынына территория яисә участок сайлау комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар тиешле территория яисә участок сайлау комиссиясе мөһере белән раслана. Территория сайлау комиссияләре акт (ведомость) буенча участок сайлау комиссияләренә сайлау бюллетеньнәре биргәндә, аларга вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларның исемлеген (әгәр андыйлар булса) һәм аларның бюллетеньнәре салынган конвертларны тапшыра. Бу хакта актта (ведомостьта) аерым юл белән билгеләнә. Тиешле участок сайлау комиссиясе сайлаучылар исемлегендә вакытыннан алда тавыш биргән гражданнарны билгеләп куя.

Сайлаулар көнне иртәнге сәгать җидедә участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирүнең башлануын игълан итә һәм сайлау комиссиясе әгъзаларына, сайлау участогына килгән сайлаучыларга һәм күзәтүчеләргә сайлау әрҗәләрен күрсәтә, шуннан соң сайлау әрҗәләре бикләнә һәм аларга мөһер сугыла. Аннары участок сайлау комиссиясе рәисе вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучылар тарафыннан тутырылган сайлау бюлллетеньнәре салынган конвертларны ача һәм андагы сайлау бюллетеньнәрен сайлау әрҗәсенә төшерә. Мондый чакта конвертлар саны игълан ителә һәм ул участок сайлау комиссиясе тарафыннан беркетмәгә кертелә. Шуннан соң гына сайлачылар сайлау бюллетеньнәре алырга чакырылалар.

Һәр сайлаучы үзе өчен үзе тавыш бирә, башка затлар өчен тавыш бирү рөхсәт ителми. Сайлау бюллетеньнәре, паспорт яисә башка шәхес таныклыгы күрсәтелгәч, сайлау участогының сайлаучылар исемлеге нигезендә сайлау комиссияе тарафыннан бирелә. Исемлеккә тиешле документның сериясе һәм номеры куела. Сайлау бюллетеньнәре алуы хакында сайлаучы үзе имза сала. Әгәр сайлаучы үзе имза сала алмаса, ул, участок сайлау комиссиясе әгъзаларыннан, күзәтүчеләрдән яисә кандидатларның ышанычлы затларыннан гайре, башка затларның ярдәменнән файдалана ала. Сайлаучыга ярдәм иткән зат сайлаучылар исемлегенең "Сайлау бюллетеньнәре алу турында сайлаучы имзасы" дигән графасына үз фамилиясен күрсәтеп имза сала.

Сайлау бюллетене яшерен тавыш бирү кабинасында яисә бүлмәсендә тавыш бирүче тарафыннан тутырыла. Сайлау бюллетеньнәре тутырганда, шушы тавыш бирүчедән гайре, бүтән бер кем дә бул-

маска тиеш. Сайлау бюллетенен мөстәкыйль тутыра алмаган сайлаучы яшерен тавыш бирү кабинасына яисә бүлмәсенә, сайлау комиссиясе әгъзасыннан, күзәтүчедән яисә кандидатның ышанычлы затыннан гайре, теләсә кемне чакыра ала.

Тавыш бирү өчен сайлау бюллетенендә сайлаучы каршы тавыш биргән Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатларның фамилияләрен сызып ташлый.

Тутырылган сайлау бюллетене сайлау әрҗәсенә төшерелә.

Сәламәтлекләре аркасында яисә башка мәгълүм сәбәпләр аркасында тавыш бирү өчен сайлау участогына килә алмаучы аерым сайлаучыларга тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге тудырылырга тиеш. Участок сайлау комиссиясе үзенең ике әгъзасына мондый сайлаучыларның язмача яисә телдән гаризасы буенча алар янына барып, урында тавыш бирүне оештырырга куша. Бу очракта күчерелмәсә сайлау әрҗәләре кулланыла, сайлау участогында аларның саны территория сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Участок сайлау комиссиясенең сайлаучылар гаризалары буенча чыгып киткән әгъзалары язмача яисә телдән бирелгән гаризалар кадәренчә сайлау бюллетеньнәре алалар, моны раслап имза салалар. Сайлау участокларыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларның фамилияләре аерым өстәмә исемлеккә кертелә, тавыш бирүче сайлау бюллетене алуы хакында исемлеккә имза сала, ә участок сайлау комиссиясе әгъзасы аны бирү хакында имза сала.

Участок сайлау комиссиясе рәисе тавыш бирү бинасындагы тәртипне күзәтеп тора. Аның әмерләрен тавыш бирү бинасындагыларның һәркайсы үтәргә тиеш. Участок сайлау комиссиясе рәисе булмаганда аны участок сайлау комиссиясе рәисе урынбасары алыштыра, ә рәис урынбасары да булмаганда - участок сайлау комиссиясе сәркәтибе яисә участок сайлау комиссиясенең вәкаләт бирелгән берәр әгъзасы алыштыра.

Әгәр яшерен тавыш бирү серен бозсалар яисә сайлаучының ихтыяр белдерүенә йогынты ясарга маташсалар, участок сайлау комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан читләштерелә, ә күзәтүче кичекмәстән тавыш бирү бинасыннан чыгарыла.

Сайлаучы сайлау бюллетенен тутырганда хата җибәрсә, ул сайлау комиссиясенең сайлау бюллетенен биргән әгъзасына, бозылганы урынына яңа сайлау бюллетене бирүен сорап, мөрәҗәгать итәргә хаклы. Сайлау комиссиясе әгъзасы сайлаучыга яңа сайлау

бюллетене бирә, бу хакта ул сайлау исемлегендә шушы сайлаучы фамилиясенең уң ягына тиешенчә билгеләп куя. Бозылган сайлау бюллетене юкка чыгарыла, бу турыда акт төзелә.

45 статья. Сайлау участогында сайлаучыларның тавышларын санау

Тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң участок сайлау комиссиясе рәисе сайлау бюллетеньнәрен бары тик тавыш бирү бинасында булган сайлаучылар гына ала алулары һәм аларның гына тавыш бирә алулары турында белдерү ясый.

Күзәтүчеләр, кандидатларны тәкъдим иткән сайлау берләшмәләре, сайлау блоклары һәм чит ил (халыкара) күзәтүчеләре катнашында, әгәр алар тавыш бирү бинасында булсалар, сайлау комиссиясе әгъзалары сайлау әрҗәләрен ачу алдыннан файдаланылмый калган сайлау бюллетеньнәрен санныйлар һәм юкка чыгаралар. Мондый сайлау бюллетеньнәренең саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә языла. Шуннан соң участок сайлау комиссиясе рәисе сайлау әрҗәләрендәге мөһерләрнең һәм пломбаларның төзеклеген тикшерә, участок сайлау комиссиясе әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм ышанычлы затларга аларны күрсәтә һәм әрҗәләрне ача. Сайлау әрҗәләре чиратлап ачыла: башта - күчерелмә сайлау әрҗәләре, аннары стационар сайлау әрҗәләре ачыла.

Сайлау бюллетеньнәрен санаганда, башта күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре санала. Күчерелмә сайлау әрҗәләреннән алынган сайлау бюллетеньнәренең саны тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү уздыруны сорап сайлаучылар тарафыннан язмача бирелгән гаризалар саныннан артмаска тиеш. Күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге бюллетеньнәр саны бирелгән гаризалар саныннан күбрәк килеп чыкканда, күчерелмә сайлау әрҗәләрендә булган барлык сайлау бюллетеньнәре участок сайлау комиссиясе карары тарафыннан дөрес түгел дип таныла. Бу факт, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган участок сайлау комиссиясе әгъзаларының фамилияләре күрсәтелеп, актка кертелә, акт исә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә өстәлә.

Сайлаучыларның тавышларын санаганда, иң элек билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр, ягъни рәсми басылмаган яисә сайлау

комиссиясе тарафыннан расланмаган бюллетеньнәр һәм гамәлгә яраксыз дип табылган бюллетеньнәр аерып алына. Тавыш биргәндә Татарстан Республикасы Президенты урынына бердән артык кандидат калдырылган булса, мондый сайлау бюллетеньнәре гамәлгә яраксыз дип саналалар. Сайлау бюллетененең дөреслегенә шик туган очракта участок сайлау комиссиясе мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә.

Сайлаучыларның тавышлары, тавыш бирү йомгакларын алганчыга кадәр, участок сайлау комиссиясе әгъзалары тарафыннан тәнәфессез саналырга тиеш, тавыш бирү йомгакларын участок сайлау комиссиясенең барлык әгъзалары, шулай ук күзәтүчеләр, шул исәптән чит илләрнең (халыкара) күзәтүчеләре дә ишетергә тиеш.

Участок сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, аңа түбәндәге мәгълүматлар кертелә:

а) өстәмә исемлеккә кертелгән сайлаучыларны да кертеп, сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның саны;

б) сайлау комиссияләре тарафыннан алынган сайлау бюллетеньнәре саны;

в) файдаланылмаган (юкка чыгарылган) сайлау бюллетеньнәре саны;

г) сайлаулар көнне сайлау участогында һәм вакытыннан алда тавыш биргән сайлаучыларга тапшырылган сайлау бюллетеньнәре саны;

д) тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

е) стационар сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны (билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрдән гайре);

ж) күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны (билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрдән гайре);

з) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саны;

и) гамәлгә яраксыз дип табылган сайлау бюллетеньнәре саны;

к) дөрес тутырылган сайлау бюллетеньнәре саны;

л) кандидатларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алда күрсәтелгәннәр бертөрле булып туры килгәндә - кандидатлар турындагы башка мәгълүматлар;

м) һәр кандидатны хуплап бирелгән тавышлар саны;

н) һәр кандидатка каршы бирелгән тавышлар саны.

Беркетмә, участок сайлау комиссиясенең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр, кандидатларның ышанычлы затлары катнашында, өч нөсхәдә төзелә һәм аларга участок сайлау комиссиясенең барлык әгъзалары имза сала. Участок сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулысынча яисә аның зерым нигезләмәләре белән килешмәгән әгъзасы беркетмәгә үз фикерен өстәп куя ала, бу хакта беркетмәдә тиешенчә язып куела.

Беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок сайлау комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм сайлау комиссиясенең алар буенча кабул иткән карарлары өстәп куела. Шикаятьләрнең (гаризаларның) һәм участок сайлау комиссиясе карарларының расланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә өстәп куела.

Участок сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, имза салынганнан соң, кичекмәстән тиешле территория сайлау комиссиясенә җибәрелә.

Беркетмәнең икенче нөсхәсе мөһерләр сугылган сайлау бюллетеньнәре белән бергә участок сайлау комиссиясе сәркәтибендә эш тәмамланганчы саклана.

Беркетмәнең өченче нөсхәсе кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә танышу өчен бирелә.

Участок сайлау комиссиясе беркетмәсендә хаталар, төгәлсезлекләр табылганда, шулай ук беркетмәнең дөрес язылуына шик туганда, тиешле участок сайлау комиссиясе сайлаучыларының тавышларын кабат санау турында югарырак сайлау комиссиясе карар кабул итә ала. Сайлаучыларның тавыш бирүләрен кабат санау, югарырак сайлау комиссиясе әгъзасы (әгъзалары) катнашында, участок сайлау комиссиясе тарафыннан уздырыла.

Сайлау документлары, сайлау бюллетеньнәрен дә кертеп, сайлауларның нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң биш көннән дә соңга калмыйча, тиешле территория сайлау комиссияләренә тапшырыла.

## 47 статья. Территория сайлау комиссияләре тавышларының йомгакларын билгеләү

Участок сайлау комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре нигезендә алардагы мәгълүматларны берләш-

теру юлы белән территория сайлау комиссиясе тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын билгели. Участок сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге мәгълүматларны территория сайлау комиссиясенең әгъзалары үзләре берләштерәләр.

Территория сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары буенча беркетмә төзи, аңа тиешле территориядәге участок сайлау комиссияләренең саны турында һәм участок сайлау комиссияләре беркетмәләре саны турында (шуларга нигезләнеп тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзелә) мәгълүматлар, шулай ук участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең әлеге Законның 46 статьясындагы алтынчы өлешендә билгеләнгән берләштерелгән мәгълүматлары кертелә.

Территория сайлау комиссиясе беркетмәсе өч нөсхәдә төзелә һәм аларга сайлау комиссиясенең шунда катнашкан барлык әгъзалары имза сала. Беркетмәгә тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблица өстәлә, анда барлык участок сайлау комиссияләре беркетмәләренең тулы мәгълүматлары бирелә. Территория сайлау комиссиясенең беркетмә белән тулысынча яисә аның кайбер нигезләмәләре белән килешмәгән әгъзасы беркетмәгә үз фикерен өстәп куя ала, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

Беркетмәнең беренче нөсхәсенә территория сайлау комиссиясенә кертелгән шикаятьләр (гаризалар) һәм сайлау комиссиясенең алар буенча кабул ителгән карарлары өстәп куела. Шикаятьләрнең (гаризаларның) һәм территория сайлау комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә өстәп куела.

Имза салынганнан соң территория сайлау комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе һәм җыелма таблица кичекмәстән Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелә.

Беркетмәнең икенче нөсхәсе һәм җыелма таблица участок сайлау комиссияләренең беркетмәләре белән бергә территория сайлау комиссиясе сәркәтибендә эш тәмамланганчы саклана.

Беркетмәнең өченче нөсхәсе һәм җыелма таблица кандидатларның ышанычлы затларына, күзәтүчеләргә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә танышу өчен бирелә.

Территория сайлау комиссиясе беркетмәсендә хаталар, тө-

гәлсезлекләр һәм башка хокук бозулар табылганда, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тиешле сайлау комиссиясе сайлаучыларының тавышларын Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең әгъзасы (әгъзалары) катнашында кабат санау турында карар кабул итә ала.

48 статья. Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре билгеләү

Территория сайлау комиссияләре беркетмәләре нигезендә алардагы мәгълүматларны берләштерү юлы белән Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе, сайлаулардан соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен билгели. Территория сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге мәгълүматларны Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясенең әгъзалары үзләре берләштерәләр.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе беркетмә төзи, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) территория сайлау комиссияләренең саны;

б) территория сайлау комиссияләренең беркетмәләре саны;

в) өстәмә исемлеккә кертелгән сайлаучыларны да кертеп, сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар саны;

г) участок сайлау комиссияләренә бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

д) файдаланылмаган (юкка чыгарылган) сайлау бюллетеньнәре саны;

е) сайлаулар көнне сайлау участокларында һәм вакытыннан алда тавыш бирган сайлаучыларга тапшырылган сайлау бюллетеньнәре саны;

ж) тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирган сайлаучыларга бирелгән сайлау бюллетеньнәре саны;

з) стационар сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре саны (билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрдән гайре);

и) күчерелмә сайлау әрҗәләрендәге сайлау бюллетеньнәре

саны (билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрдән гайре);

к) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучылар саны;

л) гамәлгә яраксыз дип танылган сайлау бюллетеньнәре саны;

м) дөрес тутырылган сайлау бюллетеньнәре саны;

н) кандидатларның фамилияләре, исемнәре һәм аталарының исемнәре, ә алда күрсәтелгәннәр бертөрле булып килгәндә - алар турында башка мәгълүматлар;

о) һәр кандидатны хуплап бирелгән тавышлар саны;

п) һәр кандидатка каршы бирелгән тавышлар саны.

Беркетмәдә түбәндәге карарларның берәрсе күрсәтелә:

1) тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның яртысыннан күбрәк тавышын җыйган кандидатны Татарстан Республикасы Президенты урынына сайланган дип тану;

2) әгәр сайлауларда сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның яртысыннан азрагы катнашса, сайлауларны узмаган дип тану. Сайлауларда катнашкан сайлаучылар саны сайлау бюллетеньнәрен алганда сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучылар имзалары саны буенча билгеләнә;

3) әгәр сайлауларны уздырганда әлеге Законны бозулар сайлаучыларның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен ышанычлы билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, сайлауларны гамәлгә яраксыз дип тану.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә һичшиксез җыелма таблица өстәлә, анда барлык территория сайлау комиссияләре беркетмәләренең мәгълүматлары бирелә.

Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында рәсми белдерү, беркетмәгә имза салынганнан соң өч көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

Территория һәм участок сайлау комиссияләренең барлык документлары алты ай саклана, тавыш бирү йомгаклары турындагы һәм сайлауларның нәтиҗәләре хакындагы беркетмәләр киләсе сайлаулар көнен билгеләгәнче саклана.

49 статья. Кабат тавыш бирү

Әгәр сайлау бюллетененә Татарстан Республикасы Президенты урынына икедән артык кандидат кертелеп, аларның берсе дә сайланмаса, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе күбрәк тавыш җыйган ике кандидат буенча Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча кабат тавыш бирүне билгели.

Кабат тавыш бирү, әлеге Законның 48 статьясындагы өченче өлешенең 2 пунктында бәян ителгән таләпләреннән гайре, калган барлык таләпләрен үтәгән килеш, сайлауларның гомуми нәтиҗәләрен билгеләгән көннән башлап ике атнадан да соңга калмыйча уздырыла. Кабат тавыш бирү турындагы белдерү, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тиешле карар кабул ителгән көненнән башлап ике көннән дә соңга калмыйча, массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

Әгәр кабат тавыш бирүне уздырганга кадәр Татарстан Республикасы Президенты урынына бер генә кандидат калган булса, Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан беренче мәртәбә кабат тавыш бирүне билгеләгәндәге һәм гомуми сайлауларда иң күп тавыш җыйган кандидатлардан соң килүче кандидат Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе карары нигезендә кабат тавыш бирүне уздыру өчен икенче кандидат итеп таныла.

Әгәр Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат, кабат тавыш бирүдә катнашучы сайлаучыларның тавышын бүтән кандидатны хуплап биргән сайлаучылар тавышына караганда күбрәк җыйса, ул сайланган дип санала, әмма кабат тавыш биргәндә кандидатны хуплап тавыш биргән сайлаучыларның тавышлары саны ике кандидатка да каршы тавыш биргән сайлаучыларның тавышларыннан күбрәк булуы шарт.

50 статья. Кабат сайлаулар

Әгәр Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар узмаган, гамәлгә яраксыз дип танылса яисә гомуми сайлауларда йә кабат тавыш биргәндә бер кандидат та Татарстан Республикасы

Президенты булып сайланмаса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Президентын кабат сайлауларны билгели.

Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидатлар тәкъдим итү һәм теркәү, кабат сайлауларны уздыруга бәйле башка сайлау гамәлләре, сайлау гамәлләренең вакытларын өчтән бергә кыскартып, Законда билгеләнгән тәртиптә уздырыла. Кабат сайлаулар уздыру турындагы белдерү массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарыла.

Кабат сайлаулар уздырган очракта, гамәлләре (эш итмәүләре) гомуми сайлауларны яисә кабат тавыш биргәндәге сайлауларны гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булган кандидатлар яңадан Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат булып тәкъдим ителә алмыйлар.

51 статья. Тавыш бирүнең йомгакларын һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен бастырып чыгару

Һәр сайлау участогы буенча тавыш бирүнең йомгаклары, тиешле сайлау комиссиясе беркетмәсендәге мәгълүматлар күләмендә һәр сайлаучыга яисә күзәтүчегә, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә танышу өчен бирелергә тиеш.

Территория сайлау комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында үз беркетмәсендәге мәгълүматларны сайлаулар узганнан соң биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгара, ә тавыш бирүнең йомгаклары турында участок сайлау комиссияләре беркетмәләрендәге мәгълүматларны сайлаулар узганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгара.

Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе, сайлаулардан соң унбиш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара.

## IX бүлек. Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе

**52 статья.** Татарстан Республикасы Президентының үз вазыйфаларына керешүе

Татарстан Республикасы Конституциясе һәм әлеге Закон нигезендә сайланган Татарстан Республикасы Президенты Татарстан Республикасы Президентын сайлауларның нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар буенча Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан рәсми белдерү ясалганнан соң, утызынчы көннән дә соңга калмыйча, үз вазыйфаларына керешә.

Яңа сайланган Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфаларына керешкәнче, Татарстан Республикасының гамәлдәге Президенты үзенең вәкаләтләрен башкара.

## X бүлек. Гражданнарның сайлау хокукларын бозган өчен җаваплылык

**53 статья.** Гражданнарның сайлау хокукларын бозган өчен җаваплылык

Алдау, сатып алу, физик көч куллану яисә көч кулланып куркыту, ялган сайлау документлары әзерләү, йә сайлаучыларның тавышларын дөрес санамау юллары белән яисә башка юллар белән Татарстан Республикасы гражданының үз сайлау хокукларын ирекле рәвештә гамәлгә ашыруына, яисә сайлау комиссияләренең йә сайлау комиссиясе әгъзаларының эшләренә тоткарлык ясаучы затлар, шулай ук кандидатлар турында ялган мәгълүматлар таратучы яисә кандидатларның намусына һәм абруена тап төшерә торган башка гамәлләр кылучы затлар, шулай ук кандидатларның ышанычлы затларының, күзәтүчеләрнең, шул исәптән чит илләрнең (халыкара) күзәтүчеләренең законлы эшчәнлегенә яисә законда билгеләнгән

тəртиптə сайлау алды үгетлəвен алып бару шартларына тоткарлык ясаучы затлар административ җаваплылыкка яисə җинаять җаваплылыгына тартылалар".

<u>2 статья.</u> Әлеге Закон басылып чыккан көненнəн үз көченə керə.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шəймиев

Казан шəһəре,
1995 елның 8 декабре
N 340

Кушымта N 2

# ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

____________________________________________________________
(район, республика буйсынуындагы шәһәр, шәһәрдәге район исеме)

Теркәү таныклыгының номеры______________________________________

Без, түбәндә имза салучылар, ______ елның _______________ туган, __________________________________________ булып эшләүче һәм ________________________________________________________ яшәүче Татарстан Республикасы гражданы ____________________________________

____________________________________________________________
(фамилиясе, исеме атасының исеме)

сайлау берләшмәсе тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат итеп тәкъдим ителүен хуплыйбыз.

| NN т/н | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (инициаллары) | Туган көне | Яшәү урынының адресы | Паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе, номеры | Имза салынган көн | Имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|

Имзалар кәгазен таныклыйм:____________________________________

____________________________________________________________
(имзалар җыючы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе һәм номеры)

(Имзалар җыючының имзасы һәм имзалар җыю көне)

Сайлаучыларның инициатив төркеме вәкиле:____________________

____________________________________________________________
(Сайлаучыларның инициатив төркеме вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе һәм номеры)

(Имза һәм имза салу көне)

248

Кушымта N 1

# ИМЗАЛАР КӘГАЗЕ

(район, республика буйсынуындагы шәһәр, шәһәрдәге район исеме)

Теркәү таныклыгының номеры ________________

Без, түбәндә имза салучылар, ______ елның ______________ туган, ________________________ булып эшләүче һәм ______________________ яшәүче Татарстан Республикасы гражданы ______________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

сайлау берләшмәсе тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты урынына кандидат итеп тәкъдим ителүен хуплыйбыз.

| NN т/н | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (инициаллары) | Туган көне | Яшәү урынының адресы | Паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе, номеры | Имза салынган көн | Имзасы |
|---|---|---|---|---|---|---|

Имзалар кәгазен таныклыйм: ______________________

(имзалар җыючы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе һәм номеры)

(Имзалар җыючының имзасы һәм имзалар җыю көне)

Сайлау берләшмәсенең вәкаләтле вәкиле: ______________________

(сайлау берләшмәсе вәкаләтле вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны, паспортының яисә аны алмаштырырлык документының сериясе һәм номеры)

(Имза һәм имза салу көне)